ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» декабрь 2019 ел № 479

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 30.05.2009 №25221-МР күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 10 мартындагы 92 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесен мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җитәкчеләрен әлеге карар белән таныштырырга һәм аны тормышка ашыру өчен чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://agryz.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гильмутдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.С. Авдеев**

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
10 декабрь 2019 № 479
Карары белән

**Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен (алга таба - компенсация) билгеләү һәм түләү механизмын билгели.

1.2. Компенсация гаиләдә җан башына уртача керем 20 000 сумнан артмаган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы карап тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 ел, 18 гыйнвар, 9 нчы карары белән билгеләнгән тәртиптә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы карап тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләүгә компенсация алучы ата - анага (законлы вәкилгә) билгеләнә һәм түләнә (алга таба-мөрәҗәгать итүче).

1.3. Гаиләнең җан башына уртача керем компенсация алу хокукы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыныц 2004 ел, 17 декабрь, 542 номерлы карары белән расланган «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнец җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасында халыкныц аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе» турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыныц 2016 елныц 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында халыкныц аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» кагыйдәләр буенча исәпләнә.

1.4. Компенсация күләме формула буенча исәпләнә:

**ДК = Ф х (100 % - МДД) - К, кайда:**

**ДК –** компенсация күләме;

**Ф -** мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы карап тәрбияләгән өчен фактта алына торган ата-ана түләве, Башкарма комитетныц тиешле елга карары белән расланган ата-ана түләве күләме чикләрендә;

**МДД -** мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасында баланы карап тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең таблица нигезендә билгеләнгән максималь рөхсәт ителгән өлеше;

**К -** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы карап тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 ел, 18 гыйнвар, 9 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү күләме.

Таблица

**Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасында баланы карап тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең максималь рөхсәт ителгән өлеше**

| Гаиләнең бер әгъзасына керем күләме | Ата-ана түләвен түләү чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше (%) | | |
|---|---|---|---|
| | Бер балага | Ике балага | Өч һәм аннан соңгы балаларга |
| мөрәҗәгать итү датасына Татарстан Республикасында билгеләнгән халыкның җан башына яшәү минимумы күләменә кадәр (18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләр өчен) | 0 | 0 | 0 |
| 10000 сумга кадәр | 60 | 38 | 23 |
| 10001 сумнан 15000 сумга кадәр | 70 | 43 | 36 |
| 15001 сумнан 20000 сумга кадәр | 80 | 53 | 53 |
| 20000 сумнан күбрәк | 100 | 100 | 100 |

1.5. Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасында баланы карап тәрбияләгән өчен гражданнар чыгымнарының максималь мөмкин булган өлешен билгеләгәндә гаилә составында исәпкә алына:

18 яше тулмаган һәм әти-әнисе карамагында тәрбияләнгән балалар, шул исәптән хастаханәләрдә дәваланучы балалар, балалар шифаханәләрендә тәрбияләнүче балалар, шулай ук интернат-мәктәпләрдә тәрбияләгән өчен ата-аналар өлешчә акча керткән балалар;

18-23 яшьлек балалар (никахта тормаучылар), ата-аналары белән бергә яшәү фактына карамастан, көндезге уку формасы буенча укучы, шул исәптән дәүләтнеке булмаган уку учреждениеләрендә белем алучы балалар;

гаиләдә яшәүче үги ул һәм үги кызлар, әгәр алар башка гаиләдә исәпкә алынмаса;

гаиләләрендә опекага алынган балалар;

тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар.

1.6. Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасында баланы карап тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенә гражданнар чыгымнарының максималь мөмкин булган өлешен билгеләгәндә гаилә составында түбәндәге балалар исәпкә алынмый:

Ике әти-әнисе дә (тулы булмаган гаиләдә әти-әниченең берсе) ата - ана

хокукыннан мәхрүм ителгән балалар;

Тулысынча дәүләт оешмалары тәэминатында торучы балалар.

## II. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе

2.1. Компенсация алу өчен мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәгенең бүлекчәсенә, ә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәгән гражданнар - тиешле мәгариф оешмасының теркәлү урыны буенча түбәндәге документларны (алга таба – Үзәк бүлеге) тапшыра:

банкта яки башка кредит оешмасында ачылган (банк яки башка кредит оешмасы аша компенсация алганда) лицевой счет реквизитларын күрсәтеп, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә компенсация билгеләү турында гариза (алга таба-гариза);

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының компенсация бирү турында гариза биргән айга кадәрге соңгы алты календарь ай эчендә керемнәрен раслый торган документлар (Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турындагы белешмәләрдән тыш);

бала (балалар) туу турында таныклык күчермәсе - бала (балалар) туу турында актны теркәү Татарстан Республикасыннан читтә башкарылган очракта;

Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасыннан, һөнәри белем бирү оешмасыннан һәм югары белем бирү мәгариф оешмасыннан уналты яшьтән алып унсигез яшькә кадәрге бала (балаларны) укытуны раслаучы белешмә,

никахлашу турындагы таныклыкның күчермәсе-никахлашу турындагы таныклыкны теркәү Татарстан Республикасыннан читтә башкарылган очракта;

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычлы затлар өчен ышаныч кәгазе;

документ (документы) (в произвольной форме) от членов семьи получателя или их законных представителей, подтверждающий (подтверждающие):

алучы гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән (ирекле формада) түбәндәгеләрне раслаучы документ (документлар):

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә рөхсәте;

гариза бирүченең шәхси мәгълүматларны органга яки оешмага тапшырганда аларның исеменнән эш итәргә вәкаләтләре.

Мөрәҗәгать итүче шәхесне раслаучы документ күрсәтә.

2.2. Үзәкнең бүлекчәсе ведомствоара сорау хатлары нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып, электрон формада, компенсация билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ала:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр - бала (балалар) туу турында актны теркәү Татарстан Республикасыннан читтә башкарылган очракта,

никах теркәү турында белешмәләр - никахлашу турындагы таныклыкны теркәү Татарстан Республикасыннан читтә башкарылган очракта;

опека (попечительлек) билгеләү, баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында, баланы карап тәрбияләү өчен опекун (попечитель) тарафыннан алына торган акчалар күләме һәм тәрбиягә бала алган ата-аналарга тиешле бүләкләү суммалары турында белешмәләр;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан эш бирүче (иминләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турында мәгълүматлар;

эшсезлек буенча пособие күләме, матди ярдәм һәм эшсез гражданнарга башка түләүләр, шулай ук һөнәри белем алу вакытында түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм, эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юнәлеше буенча өстәмә һөнәри белем алу, җәмәгать эшләрендә катнашучы гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга, вакытлыча эшләрдә катнашкан чорда түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм турында белешмәләр, шулай ук 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге гражданнарга вакытлыча эшләрдә катнашкан чорда түләүләр турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсияләр, компенсацион түләүләр һәм пенсионерларны ай саен өстәмә матди тәэмин итү күләмнәре турында белешмәләр;

Россия Эчке эшләр министрлыгы һәм Россия Оборона министрлыгы тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнары яки социаль яклау органнары тарафыннан йөклелек һәм бала табу буенча бирелә торган пособие күләме турында белешмәләр;

вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек буенча пособие күләме турында белешмәләр;

йөклелекнең иртә срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында белешмәләр;

социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган бала тәрбияләгән өчен айлык пособие күләме турында белешмәләр;

социаль яклау органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль түләүләр күләмнәре турында белешмәләр;

медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча медицина-социаль экспертиза нәтиҗәсе, һөнәри эшкә яраклылык югалган очракта, яисә иминият очрагы килеп чыккан очракта, аларны алырга хокукы булган затларга производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм иминләштерелгән гражданнарга түләнә торган һөнәри авырулардан ай саен түләнә торган иминият түләүләре күләме турында белешмәләр;

даими яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында уналты яшьтән алып унсигез яшькә кадәрге баланы (балаларны) укыту турында белешмәләр;

гариза бирүче паспортының чынлыгын раслау турында белешмәләр-Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша мөрәҗәгать иткәндә.

Мөрәҗәгать итүчеләр үз инициативасы белән үзәк бүлекчәсенә әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырырга хокуклы.

2.3. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнар ризалыгы булганда, компенсацияне билгеләү Россия Федерациясе Пенсия Фондында соңгы алты айда компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айдан алдагы 12 айдан гаилә әгъзаларының керемнәре турындагы белешмәләр нигезендә башкарыла.

2.4. Мөрәҗәгать иткән көнгә мөрәҗәгать итүче гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнгән социаль ярдәм чараларын алучы булса, мөрәҗәгать итүче керемнәр турында белешмәләр бирү вазыйфасыннан азат ителә.

2.5. Әгәр мөрәҗәгать итүче торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидия яисә балага айлык пособие түләүгә субсидия алучының гаилә составына керсә, элек аның гаризасы буенча билгеләнгән компенсация, торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларны яисә балага айлык пособиене исәпкә алып, яңадан билгеләнергә мөмкин.

2.6. Үзәкнең бүлегендә әлеге Тәртипнең 2.1 пунктының сигезенче абзацында күрсәтелгән, шулай ук әлеге Тәртипнең 2.2 пунктының алтынчы һәм җиденче абзацларында күрсәтелгән компенсацияне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән алдагы алты ай эчендә алынган белешмәләр булганда, алар компенсация билгеләгәндә кулланыла.

2.7. Гаризаны теркәгән көннән соң ун эш көне эчендә үзәк бүлеге барлык кирәкле документлар белән компенсацияне билгеләү турында карар кабул итә яки аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм тиешле карарны мөрәҗәгать итүче күрсәткән юл белән җиткерә (почта адресы буенча, электрон почта адресы, телефонга смс-хәбәр рәвешендә, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша).

2.8. Компенсация барлык кирәкле документлар белән гариза биргән айдан билгеләнә һәм алты ай дәвамында түләнә.

2.9. Гариза бирүченең компенсация алу хокукын раслый торган мәгълүматлар үзәк бүлегендә булганда, компенсация, гражданин мөрәҗәгать итмичә генә, автомат рәвештә яңа срокка билгеләнә.

2.10. Компенсацияне билгеләүдән баш тарту өчен, булган мәгълүматлар һәм документлар җыелмасы нигезендә ачыкланган, аны алуга хокук булмау нигез булып тора.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Гариза бирүче бирелгән белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар кергән документларның дөреслеге өчен җаваплы.

3.2. Законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган гариза һәм документларның күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

Компенсация алу өчен кирәкле гариза һәм документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Электрон документлар рәвешендә бирелә торган гаризалар һәм документлар (белешмәләр) Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән имзалана һәм, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы электрон чыганакларны һәм (яки) мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләрне кулланып тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче затлардан тыш, балалары булган, туу турында таныклык Татарстан Республикасыннан читтә бирелгән мөрәҗәгать итүчеләрдән тыш;

балаларының ата-анасы белән никахта тормаучы һәм ялгыз ана булып саналмаучы мөрәҗәгать итүчеләрдән тыш; никахлары Татарстан Республикасы территориясеннән читтә теркәлгән мөрәҗәгать итүчеләрдән тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша гариза җибәрә алалар; мөрәҗәгать итүчеләрдән, әгәр аның һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының керемнәре бар икән, алар турында Россия Федерациясе Пенсия фондында булмаган керемнәр (вакытлыча эшкә яраксызлык буенча түләүләрдән тыш һәм Россия Федерациясе Социаль иминият фондында яки халыкны социаль яклау бүлегендә булган аналарга бәйле рәвештә; халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре аша алына торган пособиеләр; шәхси ярдәмче хуҗалык алып барудан керемнәр) булса.

3.3. Үзәкнең бүлекчәсе мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителгән документларныц чынлыгында һәм дөреслегендә шик туган очракта бирелгән вәкаләтләр кысаларында өстәмә тикшерүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган тәкъдим ителгән документларныц өстәмә тикшерүе үткәрелгән очракта, компенсацияне билгеләү турында йә билгеләп куюдан баш тарту турында соцгы җавап мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән тикшерүне уздырганнан соц бирелә, ләкин ул Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән мизгелдән 30 көннән дә соцга калмыйча бирелә.

3.4. Компенсация суммасы мөрәҗәгать итүченец банк счетына күчерелә.

Сәламәтлеге торышы, яше яки йөри алу-алмавы аркасында банк счетын ачарга һәм алардан файдалануга мөмкинлекләре чикле мөрәҗәгать итүчегә, компенсация түләү (китерү) элемтә оешмасы аша яисә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән акчалата түләүләрне китереп торучы башка оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

3.5. Банк счетларына компенсацияне күчерү һәм почта элемтәсе белән тәэмин итү яки гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән башка оешмалар тарафыннан акча түләүләрен китерү гамәлгә ашыручы бүтән оешмалар тарафыннан исәп-хисап ае дәвамында башкарыла.

3.6. Гражданнар компенсация түләүне билгеләнгән (билгеләнә торган) түләүне туктату (мәгариф оешмасын үзгәртү, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү, мөрәҗәгать итүченең һәм/яки компенсация бирелә торган баланыц үлеме) сәбәпләренец килеп чыгуы турында үзәк бүлекчәсенә мондый хәл килеп туган мизгелдән бер айдан да соцга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

3.7. Түләүне туктатуга китерә торган шартлар килеп туганда, түләү тиешле шартлар туган айдан соц килүче айдан туктатыла.

3.8. Алучыларга хокуксыз түләнгән компенсация суммасы, шул исәптән ялган белешмәләре булган документларны тапшыру, күрсәтелгән түләүне билгеләү хокукына йогынты ясый торган мәгълүматларны яшерү, хисап хатасын яшерү нәтиҗәсендә, алучылар тарафыннан Үзәкнең казна счетына яисә булачак компенсация суммалары хисабына тулысынча кайтарылырга тиеш, ә мөрәҗәгать итүче баш тарткан очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерелергә тиеш.

3.9. Алучыга тиешле һәм Үзәк бүлеге гаебе белән вакытында түләнмәгән компенсация суммасы узган вакыт өчен, нинди дә булса срок белән генә чикләнмичә, түләнә.

3.10. Алучыга исән чакта түләнмәгән компенсация суммасы мирас составына кертелә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гомуми нигезләрдә мирас булып кала.

3.11. Компенсация бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

Кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУнең ____ номерлы бүлегенә;

______________________________________________

муниципаль районда (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ____

________ 20__ ел.

Мин,______________________________________________________________________,

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

| Шәхесне раслаучы документның исеме | Серия һәм (яки) номер | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелү датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

адрес буенча яшәүче:

________________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индекс, телефон, электрон почта адресы)

нигезендә эш итүче:

________________________________________________________________________________,

(ышанычлы зат яки законлы вәкил мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең дәүләт хезмәтен алучының мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслаучы документ реквизитлары)

Снилс (алучының) __________

Билгеләвегезне сорыйм

______________________________________________________________ ,

(дәүләт хезмәтен алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

адрес буенча яшәүче:

________________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәтен алучының почта адресы, индекс, телефон, электрон почта адресы)

________________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының шәхесен раслаучы документ реквизитлары)

___

мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсацион түләүләрен.

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тәкъдим итәм:

| № | Документлар исеме | Экземпляр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |
| 5 | | |

Түләүләр алучының гаилә составы:

| № | Ф.И.О. (туу датасы) | Туганлыгы | Паспорт (бала туу турында таныклык) реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |

Гаризада күрсәтелгән бала (балалар) тулы дәүләт тәэминатында, шулай ук аларга карата мөнәсәбәттә булмавын раслыйм:

___

(дәүләт хезмәтен алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-ана хокукларында чикләнмәгән

_________ ___________________________

(имза, расшифровка)

___

(баланы опекага алган очракта опеканы билгеләгән органның исемен һәм урынын күрсәтергә)

Уналты яшьтән өлкәнрәк бала (балалар) укый:

___________________________________ ________________________________________

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме) (гомуми белем бирү оешмасы исеме)

___________________________________ ________________________________________

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме) (гомуми белем бирү оешмасы исеме)

Билгеләнгән түләүләрне күчерергә:

счет реквизитлары ______________________________________________________________

(банкта яки башка кредит учреждениесендә законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәтен алучы яисә аның законлы вәкиле тарафыннан ачылган шәхси счет реквизитлары күрсәтелә)

Почта бүлеге реквизитлары ________________________________________________

(дәүләт хезмәтен алучының яисә аның законлы вәкиленең почта бүлеге реквизитлары күрсәтелә)

Бирелгән мәгълүматларның дөреслеге, шулай ук алар кергән документларның чынлыгы өчен җавап тотам _________________________

(имза)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да килешәм:

почта адресы буенча язма формада

телефонга смс-хәбәр итеп ________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында

электрон почта адресы буенча ____________________

(электрон почта адресы)

Татарстан Республиканың

"Дәүләт порталы

һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү”

мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша ______________________

(имза)

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга, шул исәптән, яңа срокка автоматик

билгеләнүгә, соңгы 6 айда Россия Федерациясе Пенсия фондында булган эш бирүче (иминләштерүче) тарафыннан минем файдага күчерелгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турындагы белешмәләр нигезендә, социаль ярдәм күрсәтү чараларын билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айдан алдагы 12 айдагы соңгы 6 ай эчендә компенсацион түләү билгеләү белән килешәм. ________________________________

(имза)

Гариза һәм документлар кабул ителде _________ __________ ____________________

(дата, имза, расшифровка)

______________________________________________________________________

Аеру линиясе

Расписка-уведомление

Мөрәҗәгать итүченең теркәү № _____________

Документлар саны __ бер. __ биттә

Документларны кабул итте __________ _________ _______________________ ____________

(вазыйфа) (имзаь) (расшифровка) (дата)